Татарстан Республикаы Аксубай муниципаль районы
“М. И. Абдрахманов исемендәге Яңа Ибрай урта мәктәбе”нең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мостафина Илһамия Мингали кызының педагогик эшчәнлегенә бәяләмә

Заман бүгенгесе көн укытучысына бик югары таләпләр куя: катлаулы һәм үзгәреп торучы шартларда илгә кирәкле, илне үсешкә илтүче булып яшәргә, эшләргә, социаль кыйммәтләр системасында үз урынын табарга сәләтле, төпле белемле, мәгълүмат белән эшли белүче, камиллеккә омтылучы, иҗади шәхес тәрбияләү. Ә бу укытучының үз фәнен камил белүен, иҗади фикерләвен һәм үз белемен мөстәкыйль рәвештә өзлексез күтәрүен , заман сулышын тоеп атлавын , уйлап табучы, югары әхлаклы, үз халкының тарихын, мәдәниятын белүне һәм үзенең укчыларында да шул ук сыйфатларны тәрбияләүне таләп итә. Заман таләпләрен аңлап, үз эшенең остасы булырга омтылучы “М. И. Абдрахманов исемендәге Яңа Ибрай урта мәктәбе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мостафина Илһамия Мингали кызы үз эш шигаре итеп татар мәгърифәтчеләренең өйрәтүләрен ала. Бу Р. Фәхреддиннең «Кешене иң бөек дәрәҗәгә җитештергән һәм исемнәрен соңгы буын кешеләргә калдырган нәрсә-гыйлемдер. Укытучы – гыйлем өйрәтүче. Дәрес - укытучы һәм балаларның җаннарын тәрбияләүче”, һәм Г. Ибраһимовның “Күп белүгә караганда да, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләрен табарга юллар күрсәтү-мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр. Дөрес, гыйлем өйрәтүче, белемне табарга ярдәм итүче, укуга кызыксыну, мәхәббәт тәрбияләүче кеше – укытучы. Илһамия Мингалиевнаның эш стажы-25 ел. Белеме-югары, Яр Чаллы дәүләт педагогия институтын тәмамлый.

Педагогның бөртекләп җыйган, күп уңышларга илткән эш тәҗрибәсе күпләр өчен өлге булырлык. Ул һәрдаим эзләнә, өйрәнә, эш тәҗрибәсе белән уртаклаша. Уртаклашу юллары да бик күп төрле: халыкара, республика фәнни-гамәли конференцияләре, педагогик укулар, электрон мәгарифнең предмет бергәлекләре, төрле порталлар, төрле иҗади оешмалар белән уртак эш оештыру, төрле республикакүләм, район газета һәм журналларында ачык дәресләр, мәкаләләр бастыру, укучыларны төрле фән бәйгеләренә һәм конкурсларга әзерләү, төрле семинарларда чыгышлар ясау, проектлар яклау, презентацияләр төзү, авторлык программалары төзү һ.б. Шундый тәҗрибә үрнәкләренең иң мөһимнәренә түбәндәгеләрне кертеп була: “Минем маршрутым: яңа мәктәп” II халыкара фәнни-гамәли конференциясе (2014 ел) һәм “Электрон дәреслекләр:тәҗрибә, өзлеклелек, уңышлар” III халыкара фәнни-гамәли конференциясе (2015 ел) ; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан оештырылган “Нәҗип Думавиның дини-фәлсәфи, мәдәни-педагогик карашлары һәм XXI гасыр” фәнни-гамәли конференциясе (2013 ел), “Халык язучыы, күренекле драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган укучылар һәм укытучылар конференциясе (2014 ел), “Укучыларны фәнни –тикшеренү һәм проект эшләренә өйрәтү методикасы” вебинары (2015 ел),

укытучыларның август киңәшмәләрендә “Мәктәп кысаларында укучыларның һәм укытучыларның фәнни – эзләнү, тикшеренү эшләрен оештыру” (2014 ел), “Укучыларны Бердәм дәүләт имтиханына һәм Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләү тәҗрибәсе” (2015), регионара семинар “Милли мәгариф өлкәсендә эзләнүләр”. Шулай ук төрле бергәлекләрдә, сайтларда даими эш алып бара: бөтенроссия “Педагогик остаханә” дистанцион мәгариф үзәге, мәгариф хезмәткәрләренең социаль челтәре, электрон мәгариф бергәлекләре шундыйларга керә. Төрле юнәлеш буенча дәрес эшкәртмәләрен дә матбугат битләрендә даими бастырып килә: “Мәгариф” журналының электрон форматы (“Фигыльләрне гомумиләштереп кабатлау” ), “Ачык дәрес” республикабызның укытучылар өчен татар телендә методик ярдәмлеге ( июнь №6 (132), 2014 ел, “Балачагым хатирәләре” ; (май №5 (143), 2015 ел, “Саннарны гомумиләштереп кабатлау”, “Көмеш кыңгырау” балалар һәм яшүсмерләр газетасында (даими) “Укучыларның иҗади эшләре”. Бу дәресләр Сингапур структурасы нигезендә, Ә. З. Рәхимовның үстерелешле белем бирү технологиясенә, Федераль белем бирү стандартлары нигезендә оештырылып алып барыла, һәр дәрескә презентация, проектлар булдырыла. Илһамия Мингалиевна “Туган якның әдәбияты һәм мәдәнияты” исемле авторлык программасы нигезендә 9 нчы сыйныф укучылары белән профиль алды әзерлеге алып бара. Авторлык программасы Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Ахатова Зифа Фәрит кызы тарафыннан рецензияләнгән (2014 ел).

Укытучы шулай ук укучылар белән Халыкара, регионара, республика фән бәйгеләрендә даими катнаша һәм призерлыкка ирешә. Мондый фән бәйгеләренә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Казан Федераль Университеты бергәлегендә үткәрелгән “Татарга тылмач кирәк”, “Татар теле һәм әдәбияты фәннәреннән халыкара фән бәйгесе”, “Татар теленнән КФУ регионара фән бәйгесе”, “Татар теле-инфо фән бәйгесе”, “Зирәк Тиен” уен-конкурсы керә. Бу бәйгеләрдә укучылар даими катнашып, призер, дипломантлар булалар (2013-2016 еллар). Ахыргы 3 ел аралыгында укучыларның иҗат бәйгеләрендә яулаган уңышлары да шактый. Болар: “Шигъри Сабантуй-2014» бөтенроссия яшь шагыйрьләр бәйгесе – 3нче дәрәҗәле диплом(2014 ел), “Татарстан – бөек һәм газиз” республикакүләм эзләнү- тикшеренү эшләре конкурсы – 3 нче дәрәҗәле диплом (2014 ел), V һәм VI бөтенроссия “Илһамлы каләм” әдәби әсәрләр конкурсы- 2нче һәм 3 нче дәрәҗәле дипломнар(2014, 2015 еллар), XIII һәм XIV “Иделем акчарлагы” яшь язучылар бәйгесе – төрле жанрлар буенча 3 нче дәрәҗәле дипломнар(2013, 2014 еллар) , “Илһам” бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе – дипломнар һәм Гран-при (2014, 2015 нче еллар) , “Сәләткә нур булган йолдызлар” республикакүләм ачык әдәби ярыш – 3 дәрәҗәле диплом (2015 ел), “Алиш эзләреннән” I төбәкара фәнни-гамәли конференция – 1 нче дәрәҗәле диплом (2014 ел) , «Гаяз Исхакыйга багышланган” фәнни-гамәли конференция – 1 нче һәм 3 нче дәрәҗәле дипломнар (2013 ел) , Аксубай район башлагы гранты иясе (2015 ел) һ. б.. Укытучы

үзе дә укучыларының мондый зур җиңүләргә ирешүләре өчен бик күп республикакүләм Мактау грамоталарына, Рәхмәт хатларына, дипломнарга, Аксубай район башлагы грантына ия. Укытучының укучыларны Бердәм республика имтиханына әзерләү күрсәткече дә бик югары – 92 балл (2015 ел). Укытучы үзе дә Республика мониторинг үзәге оештырган экспертар әзерләү семинарларында катнашты (2014 ел). 2013, 2014 нче елларда Мәгариф министрлыклары тарафыннан үткәрелгән төрле һөнәри проектларда, конкурсларда катнашты: “Безнең иң әйбәт укытучы”, “Ел укытучысы-2014”, “Цифрлы гасыр мәктәбе”бөтенроссия проектында “Цифрлы гасыр укытучысы” дипломанты.

2002 нчы елдан бирле мәктәп Советы составында уку эшләрен , 2010 нчы елдан бирле мәктәпнең сыйныф җитәкчеләре берләшмәсен җитәкли. Ә бу үз чиратында зур җаваплылык сорый, чөнки ул башка педагогларга остаз булырга тиеш.

Хәзерге чорда ана теле һәм әдәбияты укытучылары да һәр яңалыктан, шул исәптән яңа технологияләрдән файдалана, аларны отышлы итеп сайлап алырга тиешләр. Илһамия Мингали кызы үз эшендә үстерелешле белем бирү, уен, проблемалы-эзләнү, информацион-коммуникатив, сәламәтлекне саклау технологияләренә, федераль стандарт үзенчәлекләре буенча проект эшчәнлегенә , Сингапур структураларына, төркемнәрдә эшләү төрләренә өстенлек бирә. Укучыларның белем сыйфаты югары.

Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
“Мәгариф бүлеге” башлыгы: Ә. К. Вәлиуллина